ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ КАЙБИЦКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

18. 09. 2025 Олы Кайбыч ав. № 407

Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитетының «Олы Кайбыч авылыннан 11 километр ераклыкта урнашкан ерак һәм аз кешеле торак авыл пунктларына товарлар илтүгә бәйле кулланучылар кооперациясе оешмаларының чыгымнары өлешен каплауга Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2017 елның 15 декабрендәге 494 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясе Бюджет кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү һәм 2022 елда Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларын үтәү үзенчәлекләрен билгеләү турында» 2021 елның 29 ноябрендәге 384-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР ИТӘ:

1. Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитетының «Олы Кайбыч авылыннан 11 километр ераклыкта урнашкан ерак һәм аз кешеле торак авыл пунктларына товарлар илтүгә бәйле кулланучылар кооперациясе оешмаларының чыгымнары өлешен каплауга Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2017 елның 15 декабрендәге 494 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 1нче кушымтада:

- түбәндәге эчтәлекле 2.6.1. пункт белән тулыландырырга:

«2.6.1. Кайбыч муниципаль районы башкарма комитеты һәм «Кайбыч муниципаль районының контроль-хисап палатасы» муниципаль казна учреждениесе субсидия алучыларга карата, алар тарафыннан субсидияләр бирү тәртибенең һәм шартларының үтәлүенә, шул исәптән аларны бирү нәтиҗәләренә ирешү өлешендә, шулай ук Россия Федерациясе Бюджет кодексының 268.1 һәм 269.2 ст. нигезендә тикшерүләр уздыра.»;

- 2.9. пунктында «субсидия бирүчеләргә һәм Кайбыч муниципаль районының муниципаль финанс контроле органнары тарафыннан субсидияләр алучыларның субсидияләр шартларын, максатларны һәм аларны бирү тәртибен

үтәүләрен тикшерүләрне.» «субсидия бирүчегә, һәм Кайбыч муниципаль районының муниципаль финанс контроле органнарына Россия Федерациясе Бюджет кодексының 78 статьясындагы 3 пунктының 5 бүлегендә каралган тикшерүләр.» сүзләренә алмаштырырга;

1.2. Тәртипкә кушымтаның 2.1.2. пунктында приложения «бюджет законнарын үтәү өлкәсендә муниципаль финанс контролен гамәлгә ашыруга субсидияләр алучы тарафыннан шартлар, максатлар һәм аларны бирү тәртибе үтәлешен тикшерүләр үткәрү.» сүзләрен «Россия Федерациясе Бюджет кодексының 78 статьясындагы 3 пунктының 5 пунктчасында каралган бюджет законнарын үтәү өлкәсендә муниципаль финанс контролен гамәлгә ашыруга.» сүзләренә алмаштырырга;

1.3. Олы Кайбыч авылыннан 11 километр ераклыкта урнашкан ерак һәм аз кешеле торак авыл пунктларына товарлар илтүгә бәйле кулланучылар кооперациясе оешмаларының чыгымнары өлешен каплауга Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы бюджетыннан субсидияләр бирү комиссиясе составын әлеге карарга кушымта нигезендә яңа редакциядә бәян итәргә.

2. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://kaybici.tatarstan.ru веб-адресы буенча Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматы рәсми порталында» бастырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесенең икътисадый мәсьәләләр буенча урынбасары Э.Х. Заһидуллинага йөкләргә.

Җитәкче А.Н. Макаров

Татарстан Республикасы
Кайбыч муниципаль районы
Башкарма комитетының
2025е. 18.09
407 номерлы карарына
кушымта

Олы Кайбыч авылыннан 11 километр ераклыкта урнашкан ерак һәм аз кешеле торак авыл пунктларына товарлар илтүгә бәйле кулланучылар кооперациясе оешмаларының чыгымнары өлешен каплауга Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы бюджетыннан субсидияләр бирү комиссиясе составы

| т/б № | Вазыйфа | Ф.И.А. |
|---|---|---|
| 1 | Рәис- Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе | А.Н. Макаров |
| 2 | Рәис урынбасары - Башкарма комитет Җитәкчесенең икътисадый мәсьәләләр буенча урынбасары | Э.Х. Заһидуллина |
| | Комиссия әгъзалары: | |
| 3 | Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитетының территориаль үсеш буенча башлыгы | И.Ф. Ильясова |
| 4 | Кайбыч муниципаль районы Финанс-бюджет палатасы рәисе | Л.Г. Михайлова |